ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22 октябрь 2024ел № 6968

«2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, шәһәр Уставының 53 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын тормышка ашыру чараларын финанслауны шәһәр бюджетында «Яшьләр сәясәте һәм балаларны сәламәтләндерү» 0707, «Мәгариф өлкәсендәге башка мәсьәләләр» 0709, «Мәдәният» 0801 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына тәэмин итәргә: 2025 елда – 2066,8 мең сум, 2026 елда – 2066,8 мең сум, 2027 елда – 2066,8 мең сум.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2024 елның 22 октябрендәге
6968 номерлы карарына
кушымта

«2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт
милли сәясәтен тормышка ашыру»
муниципаль программасы

1 бүлек. «2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт
милли сәясәтен тормышка ашыру»
муниципаль программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2025-2027 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру программасы» (алга таба – программа). |
| Программаны эшләү өчен нигез (хокукый актның исеме, номеры һәм датасы) | Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең дәүләт милли сәясәте стратегиясе.<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 15 апрелендәге 317 номерлы карары белән расланган «Мәдәниятне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы.<br>Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Дәүләт милли сәясәте концепциясен раслау турында» 2008 елның 3 июлендәге ПУ-312 номерлы Указы.<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы карары белән расланган «2014-2025 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасы |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе (алга таба – мәдәният идарәсе). |
| Программаны үтәүчеләр | Мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе. |
| Программаның максаты | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче халык вәкилләренең цивилизацияле үсеше, этникара һәм конфессияара татулыкны һәм бердәмлекне саклау, гомумроссия гражданлык тәңгәллеген (Россия милләтенең) ныгыту, мигрантларның |

<table>
<tr><td></td><td colspan="5">уңышлы социомәдәни адаптациясе һәм интеграциясе.</td></tr>
<tr><td>Программаның бурычлары</td><td colspan="5">1. Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәте өлкәсендә муниципаль органнарның гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара эшчәнлеген камилләштерү.<br>2. Гомумроссия гражданлык тәңгәллеген ныгытуга, этникара һәм конфессияара татулыкны һәм бердәмлекне саклауга булышлык итү, мигрантларның социомәдәни адаптациясе һәм интеграциясе өчен шартлар тудыру.<br>3. Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни үсеше өчен шартлар тудыру.<br>4. Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруның фәнни-белем бирү һәм мәгълүмати тәэмин ителеше.</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td colspan="5">2025-2027 еллар</td></tr>
<tr><td rowspan="8">Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары</td><td rowspan="2">Финанслау чыганаклары</td><td colspan="4">Программаны тормышка ашыру еллары</td></tr>
<tr><td>2022 ел</td><td>2023 ел</td><td>2024 ел</td><td>Тормышка ашыру чорында барлыгы (мең сум)</td></tr>
<tr><td>Муниципаль бюджет</td><td>2 066,8</td><td>2 066,8</td><td>2 066,8</td><td>6 200,4</td></tr>
<tr><td>Федераль бюджет</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Республика бюджеты</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Башка чыганаклар</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>2 066,8</td><td>2 066,8</td><td>2 066,8</td><td>6 200,4</td></tr>
<tr><td colspan="5">Искәрмә: финанслау күләмнәре прогноз характерга ия һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, аларга ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре</td><td colspan="5">Программаны тормышка ашыруның йомгаклау нәтиҗәләре:<br>- интернационализм, бердәмлек, милли һәм дини үзара килешүчәнлек культурасын тарату;<br>- башка этникара һәм конфессияара җәмгыятьләрнең вәкилләренә карата толерантлы аң формалаштыру;<br>- яшьләр мохитендә этникара бердәмлек һәм толерантлык атмосферасын ныгыту һәм җәелдерү;</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | - муниципаль берәмлек территориясендә толерантлык, гражданнар бердәмлеге, башка мәдәниятләргә хөрмәт белән карау идеяләрен пропагандалау һәм тарату өчен бердәм мәгълүмати киңлек булдыру, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша. |
| Программаны тормышка ашыруга контроль оештыру системасы | Программа үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет гамәлгә ашыра. |

2 бүлек. Проблеманың эчтәлеге һәм аны программа алымы белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Программа Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Дәүләт милли сәясәте концепциясен раслау турында» 2008 елның 3 июлендәге ПУ-312 номерлы Указы нигезендә эшләнде. Әлеге Концепция нигезендә, Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең милләтара мөнәсәбәтләре һәм этномәдәни үсеш өлкәсе дәүләт милли сәясәтенең объекты булып тора.

Татарстан Республикасының Дәүләт милли сәясәте концепциясе принципларына таянып, Программа, милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруның, Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыклар вәкилләренең этномәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен оптималь шартлар тудыруның максатларын, принципларын, төп юнәлешләрен, бурычларын һәм механизмнарын билгели.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә милләтара мөнәсәбәтләрнең торышы тотрыклылык, үзара татулык һәм төрле этник төркемнәр һәм конфессияләр вәкилләренең хезмәттәшлеге белән характерлана. Үзара ихтирам һәм ышанычка корылган милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр муниципаль хакимият органнарының иҗтимагый этномәдәни берләшмәләр һәм башка гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара эшчәнлегендә аеруча кайгыртучанлык предметы булып тора.

Яр Чаллы шәһәре хәзерге заман Татарстан территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең тыгыз этномәдәни үзара йогынтысы һәм традицияләрнең үзара саклануы белән характерлана торган күпмилләтле һәм поликонфессияле Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге санала. Әлеге процесста традицион рәвештә әйдәп баручы ролен Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче барлык калган халыклар вәкилләренә карата күпчелекне тәшкил иткән татар һәм рус халыклары вәкилләре уйный.

Төрле мәдәният һәм дин вәкилләренең Яр Чаллы шәһәрендә күп еллар бергә яшәү дәверендә барлыкка килгән дус-туганлык традицияләре хәзерге вакытта да саклана. Гомумроссия гражданлык тәңгәллеген формалаштыру, яшь буынны Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең мәдәниятенә, теленә, традицияләре һәм гореф-гадәтләренә хөрмәт белән карау рухында тәрбияләү, белем бирү процессында гуманитар юнәлешнең ролен күтәрү буенча максатчан эшләү моңа ярдәм итә.

Милли җәмгыятьләр каршында 11 милли мәдәниятне сөючеләр клубы эшли, алар: «Хары - Бюльбюль» азәрбайҗан мәдәниятен сөючеләр клубы, «Наири» әрмән мәдәниятен сөючеләр клубы, «Киликиа» әрмән мәдәниятен сөючеләр клубы, «Эрвий» мари мәдәниятен сөючеләр клубы, «Inspiration» яшьләр клубы – немец мәдәниятен сөючеләр клубы, «Лезгияр» лезгин мәдәниятен сөючеләр клубы, «Кизилиос» удмурт мәдәниятен сөючеләр клубы, «Гөрләвек» башкорт мәдәниятен сөючеләр клубы, «Игенэй» керәшен мәдәниятен сөючеләр клубы, «Путене» чуаш мәдәниятен сөючеләр клубы, таҗик мәдәниятен сөючеләр клубы. Аларда талантлы укытучылар – милли җәмгыятьләрнең педагогик белемгә ия вәкилләре хезмәт куя. Һәр клубта уртача 15 әр

кеше шөгыльләнә, барлыгы төрле яшьтәге 150 кеше зур канәгатьләнү белән милли клубларның дәресләренә йөри.

Идарә системасы, мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте һәм массакүләм мәгълүмат чаралары кадрларының этномәдәни үсеш, милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр, мигрантларны хокукый агарту, аларның җәмгыятьтәге социомәдәни адаптациясе һәм интеграциясе мәсьәләләрендә квалификацияләрен һәм компетентлыгын күтәрү мөһим бурыч булып тора.

Конфессияара татулык һәм бердәмлекне, мигрантларның социомәдәни адаптациясен һәм интеграциясен тәэмин итүдә гражданлык җәмгыяте институтлары зур роль уйный. Алар арасында Татарстан халыклары Ассамблеясының Яр Чаллы филиалы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы дини һәм иҗтимагый оешмалар белән үзара эшчәнлек Советы мөһим урын тота.

Шәһәрдә 38 дини оешма, шул исәптән 18 – мөселман, 11 – православие, 1 – рус правосавие иске дин җәмгыяте, 7 – протестант, 1 яһүд оешмасы бар.

Традицион дини агымнар вәкилләре үз хезмәтләрен башкарганда халык арасында дини һәм конфессияара конфликтлар килеп чыгуны булдырмауга юнәлдерелгән агарту эшләре алып баралар.

Дин башлыклары шәһәр һәм район чараларында актив катнашалар, агарту эше белән шөгыльләнәләр.

Традицион дини берләшмәләр Башкарма комитет белән даими үзара эшчәнлек алып баралар.

Муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарының милли һәм дини берләшмәләр җитәкчеләре белән үзара эшчәнлеге нәтиҗәсендә 2024 елда Яр Чаллы шәһәре территориясендә милләтара һәм динара конфликтлар булмады.

Милләтара мөнәсәбәтләрне үстерү һәм гармонияле итү проблемасы комплекслы якын килүне, аны максатчан программа алымнары белән хәл итүне сорый. Аларга түбәндәгеләр кирә:

- этникара интеграция һәм бердәмлек проблемасының масштаблылыгы һәм күпкырлылыгы;
- милләтара мөнәсәбәтләрне җайга салу процессының күп аспектлылыгы;
- муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче халыклар һәм төрле этник төркемнәр вәкилләре арасында гомумгражданлык бердәмлеген формалаштыру процессының социаль, этник һәм икътисадый аспектларының үзара бәйлелеге;
- дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруда, этноконфликтларны һәм экстремизмны профилактикалауда җирле үзидарә органнарының, милли-мәдәни берләшмәләрнең һәм дини берләшмәләрнең үзара эшчәнлек зарурлыгы.

Программа муниципаль берәмлектә милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең позитив характерын саклауга һәм үзара хөрмәт һәм дус-туганлыкның күп гасырлар буена яшәп килгән традицияләре нигезендә гражданнарның этномәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә булышлык итүгә юнәлдерелгән. Программа этникара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге проблемаларны булдырмау һәм Яр Чаллы шәһәре күпмилләтле халкының этномәдәни үсешен яхшырту мөмкинлеге бирәчәк.

## 3 бүлек. Программаның тормышка ашыру сроклары һәм этаплары күрсәтелгән төп максатлары, бурычлары

Программаның максаты – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең цивилизацияле үсеше, этникара һәм конфессияара тынычлыкны һәм татулыкны саклау, гомумроссия гражданлык

тәңгәллеген (Россия милләтенең) ныгыту, мигрантларның социомәдәни адаптациясе һәм интеграциясе.

Программаның бурычлары:

1) Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәте өлкәсендә муниципаль органнарның гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара эшчәнлеген камилләштерү;

2) Гомумроссия гражданлык тәңгәллеген ныгытуга, этникара һәм конфессияара татулыкны һәм бердәмлекне саклауга булышлык итү, мигрантларның социомәдәни адаптациясе һәм интеграциясе өчен шартлар тудыру;

3) Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни үсеше өчен шартлар тудыру;

4) Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруның фәнни-белем бирү һәм мәгълүмати тәэмин ителеше.

Күрсәтелгән максатлар һәм бурычларны үтәүгә ирешү программага кергән чаралар кысаларында гамәлгә ашырылачак.

| № т/б | Этапның исеме | Тормышка ашыру чоры |
|---|---|---|
| 1 | Программаны тормышка ашыру | 2025-2027 еллар |
| 2 | Йомгаклау | 2027 елның 4 кварталы |

4 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

| Чыгымнарның чыганаклары һәм юнәлешләре | Финанслауның күләме (мең сум) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | Шул исәптән еллар буенча | | |
| | | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 6 200,4 | 2 066,8 | 2 066,8 | 2 066,8 |
| Барлыгы | 6 200,4 | 2 066,8 | 2 066,8 | 2 066,8 |

5 бүлек. Нәтиҗәлелекне бәяләү һәм көтелгән нәтиҗәләр

Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеге төрле халыклар вәкилләренең толерантлыгы һәм мәдәнияткә, телгә һәм традицияләргә ихтирамы үсү нигезендә бәяләнә. Социаль тотрыклылыкны, этникара һәм конфессияара тынычлыкны һәм этномәдәни үзенчәлекне саклау һәм Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыклар вәкилләренең социаль-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү.

Программаны тормышка ашыру түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:

- Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни үсеше өчен шартларны яхшырту;
- мигрантларның социомәдәни адаптациясе һәм интеграциясе дәрәҗәсен саклау.

| № т/б | Индикаторның исеме | Исәпләү формуласы |
|---|---|---|
| 1. | Яр Чаллы шәһәрендә милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияле итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучыларның өлеше | $\frac{N}{D} * 100\%$<br>N – Яр Чаллы шәһәрендә милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияле итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучыларның саны;<br>D – Яр Чаллы шәһәрендә милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияле итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучыларның гомуми саны. |
| 2. | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни (бу – гражданнарның этник, этномәдәни яки дини принциплар буенча традицион эшләүче яки күптән түгел үзеннән-үзе оешкан берләшмәләр) үсешенә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни үсешенә юнәлдерелгән чараларда катнашучыларның санын ел саен арттыру планлаштырылган. |

6 бүлек. Нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, программа чаралары һәм чаралар буенча финанслау

| № т/б | Чараларның исеме | Башкару чылар | Тормышка ашыру сроклары | Максатчан индикаторлар һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганаклары | Чыганакны күрсәтеп, финанслау күләме, мең сум | | | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2024 ел (бәяләү) | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | |
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| Максатларның исеме: Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәүче халыклар вәкилләренең цивилизацияле үсеше, этникара һәм конфессияара тынычлыкны һәм дуслыкны саклау, гомумроссия гражданлык тәңгәллеген (Россия милләтенең) ныгыту, мигрантларның социомәдәни адаптациясе һәм интеграциясе | | | | | | | | | | | | | |
| 1. | | | 2025-2027 еллар | Яр Чаллы шәһәрендә милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияле итүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучылар өлеше, % | 68,4 | 69,6 | 70 | 70,4 | | | | | |
| 2. | | | 2025-2027 еллар | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни үсешенә | 55 120 | 56 525 | 57 715 | 58 120 | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны, кеше | | | | | | | | | |

| № т/б | Чараларның исеме | Башкаручылар | Тормышка ашыру сроклары | Максатчан индикаторлар һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганаклары | Чыганакны күрсәтеп, финанслау күләме, мең сум | | | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2024 ел (бәяләү) | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел | |
| | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| Бурычның исеме: 1. Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәте өлкәсендә дәүләт һәм муниципаль органнарның гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара эшчәнлеген камилләштерү | | | | | | | | | | | | | |
| 1. | Чараларны оештыручылар ягыннан «Җыелышлар, митинглар, демонстрация лар, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә гавами чаралар оештыру һәм | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | 2025-2027 еллар | Үткәрелгән гавами чаралар буенча әзерләнгән хисаплар саны, берәмлек | 45 | 46 | 47 | 48 | - | - | - | - | Гомумроссия граждан (Россия милләтенең) тәңгәллеген ныгыту |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | үткәрү тәртибен саклауны тәэмин итү | | | | | | | | | | | |
| 2. | Милли һәм дини нигездә экстремизмны профилактикалау максатында милли диаспоралар, милли-мәдәни җәмгыятьләр лидерлары һәм вәкилләре белән регуляр очрашулар үткәрү | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | 2025-2027 еллар | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - | - | Шәһәрдә яшәүче халыкларның милли-мәдәни үсеше |
| 3. | Милли җәмгыятьләр рәисләренең Татарстан халыклары Ассамблеясының Күчмә утырышларында катнашуы | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - | - | Шәһәрдә яшәүче халыкларның милли-мәдәни үсеше, милли һәм дини нигездә экстремизмны профилактикалау |
| Бурычның исеме: 2. Гомумроссия гражданлык тәңгәллеген ныгытуга, этникара һәм конфессияара татулыкны һәм бердәмлекне саклауга булышлык итү, мигрантларның социомәдәни адаптациясе һәм интеграциясе өчен шартлар тудыру. | | | | | | | | | | | | |
| 4. | Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында, «Интернет» челтәрендә этникара һәм динара мөнәсәбәтләр не ныгытуга, дини һәм | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында чыккан | 11 | 12 | 13 | 14 | - | - | - | - | Шәһәрдә милләтара һәм конфессияара бердәмлеккә булышлык итү өчен уңай атмосфера |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | этник түзеп тора алмаучанлык һәм дискриминациягә каршы торуга булышлык итә торган мәгълүматлар урнаштыру, шулай ук шәһәрдә үткәрелә торган этникара һәм динара мөнәсәбәтләр не ныгытуга булышлык итә торган чараларны яктыртып бару | | | мәкаләләр саны, берәмлек | | | | | | | | | булдыру |
| 5. | Дини оешмаларга конфессияара үзара аңлашуга һәм татулыкка булышлык иткән мәдәни-агарту һәм хәйрия программаларын тормышка ашыруда ярдәм күрсәтү (Раштуа, Пасха, Чукындыру хөрмәтенә тәре йөреше, Ураза бәйрәме, Корбан бәйрәме, Хәтер көннәре) | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | Фактта | Фактта | Фактта | Фактта | - | - | - | - | Шәһәрдә милләтара һәм конфессияара бердәмлеккә булышлык итү өчен уңай атмосфера булдыру |
| 6. | Казан епархиясе рус православие чиркәвенең Кама аръягы благочиниесы | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм | 2025-2027 еллар | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 8 | 8 | 8 | 8 | - | - | - | - | Шәһәрдә милләтара һәм конфессияара бердәмлеккә |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | һәм ТР мөселман нарының Диния нәзарәте мөхтәсибәтенең берләктә эшләве өчен шартлар тудыру: социаль, хәйрия чаралары, үзара визитлар, түгәрәк өстәлләр һ.б. | җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | | | | | | | | | | булышлык итү өчен уңай атмосфера булдыру |
| 7. | «Ак мәчет» мәчетендә яшь Коръән укучыларның ел саен үткәрелә торган республикаара конкурсын уздыруда ярдәм күрсәтү | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 171 | 172 | 173 | 174 | - | - | - | - | Шәһәрдә милләтара һәм конфессияара бердәмлеккә булышлык итү өчен уңай атмосфера булдыру |
| 8. | Милли җәмгыятьләр рәисләренең квартал саен Федераль Миграция хезмәте идарәсе вәкилләре белән очрашуы | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Үткәрелгән чаралар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - | - | Шәһәр территориясендә яшәүче халыкларның милли-мәдәни үсеше, милли һәм дини нигездә экстремизмны профилактикалау |
| Бурычның исеме: 3. Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның этномәдәни үсеше өчен шартлар тудыру | | | | | | | | | | | | |
| 9. | «Илһамлы каләм» республика конкурсының муниципаль турын оештыру | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 1 030 | 1 035 | 1 040 | 1 045 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 25,0 | 25,0 | 25,0 | Балаларны һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 10. | Идел буе халыкларының «Мәдәниятләр диалогы» фестивален оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 65 | 70 | 75 | 80 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 30,0 | 30,0 | 30,0 | Балаларны һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 11. | «Татар малае» мунииипаль конкурсын оештыру һәм үткәрү (1-4 сыйныфлар) | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 130 | 135 | 140 | 145 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Балаларны һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 12. | «Татар малае» мунииипаль конкурсын оештыру һәм үткәрү (5-8 сыйныфлар) | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 130 | 135 | 140 | 145 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Балаларны һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 13. | «Татар малае», «Татар кызы» мунииипаль конкурсын оештыру һәм үткәрү (мәктәпкәчә яшьтәгеләр) | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 230 | 235 | 240 | 245 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 70,0 | 70,0 | 70,0 | Балаларны һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 14. | «Мин татарча сөйләшәм» республика конкурсының муниципаль турын оештыру | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 130 | 135 | 140 | 145 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 25,0 | 25,0 | 25,0 | Балаларны һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 15. | «Татар кызы» мунииипаль конкурсын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 73 | 75 | 80 | 83 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Мәктәп яшендәге балаларны мәдәни-тарихи социальләштерү |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | бюджеты | | | |
| 16. | Туган тел көнен үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 70 | 73 | 77 | 80 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 30,0 | 30,0 | 30,0 | Балаларны һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 17. | «Бердәмлек» шәһәр программасын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 1 030 | 1 035 | 1 040 | 1 045 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 25,0 | 25,0 | 25,0 | Балаларны һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 18. | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең балалар коллективлары арасында «XXI гасыр йолдызчыклары» муниипаль конкурсын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 330 | 335 | 340 | 345 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 19. | Гаилә, мәхәббәт һәм тугрылык сакчылары изге Петр һәм Феврония Муромскийлар истәлеге көненә чаралар оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 330 | 335 | 340 | 345 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 30,0 | 30,0 | 30,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 20. | Милли җәмгыятьләр спартакиада сын оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачы | 230 | 235 | 240 | 245 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль | 15,0 | 15,0 | 15,0 | Бердәм мәдәни киңлек формалаштыру, шәһәрдә |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | лар саны, кеше | | | | | бердмлеге бюджеты | | | | яшәүче халыклар вәкилләренең милли спорт төрләрен, традицион уеннарны популярлаш тыру |
| 21. | «Ариран» корея җәмгыяте белән берлектә Көнчыгыш Яңа елын оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучы лар һәм тамашачы лар саны, кеше | 180 | 190 | 200 | 210 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 5,0 | 5,0 | 5,0 | Корея халыкларының мәдәни төрлелеген һәм традицияләрен саклау |
| 22. | Таҗик, лезгин, азербайҗан, үзбәк, казах, башкорт җәмгыятьләрендә «Нәүрүз» милли бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучы лар һәм тамашачы лар саны, кеше | 235 | 240 | 245 | 250 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 10,0 | 10,0 | 10,0 | Халыкларны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 23. | Яр Чаллы шәһәрендә «Нәүрүз» милли бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучы лар һәм тамашачы лар саны, кеше | 585 | 590 | 595 | 600 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Халыкларны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 24. | «Немец мәдәнияте көне» чарасын оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучы лар һәм тамашачы лар саны, кеше | 150 | 160 | 170 | 180 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 5,0 | 5,0 | 5,0 | Немец халкы мәдәнияте төрлелеген һәм традицияләрен саклау |
| 25. | «Уяв» чуаш милли- | Мәдәният | 2025- | Катнашучы | 225 | 230 | 235 | 240 | Яр Чаллы | 30,0 | 30,0 | 30,0 | Халыкны мәдәни- |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | йола бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | идарәсе | 2027 еллар | лар һәм тамашачы лар саны, кеше | | | | | шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | | | | тарихи социальләштерү |
| 26. | «Иван Купала» славян халык-йола бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучы лар һәм тамашачы лар саны, кеше | 1 035 | 1 035 | 1 040 | 1 045 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 75,0 | 75,0 | 75,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 27. | «Питрау» шәһәр халык-йола бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучы лар һәм тамашачы лар саны, кеше | 665 | 670 | 675 | 680 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 75,0 | 75,0 | 75,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 28. | «Нардуган» традицион керәшен йола бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучы лар һәм тамашачы лар саны, кеше | 300 | 300 | 300 | 300 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 29. | Мәктәпкәчә белем бирү учреждение ләрендә тәрбияләнүче ләр өчен «Салават күпере төсләре» күңел ачу-танып-белү программасы | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Концертлар саны, берәмлек | 16 | 17 | 18 | 19 | - | - | - | - | Балаларны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 30. | Милли җәмгыятьләр яшьләре өчен «Мәхәббәт хакына» конкурс-күңел ачу программасы | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучы лар һәм тамашачы лар саны, кеше | 283 | 283 | 283 | 283 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 15,0 | 15,0 | 15,0 | Яшьләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 31. | Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен «Милли курчак» шәһәр конкурсы | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Конкурста катнашучылар саны, кеше | 14 | 14 | 14 | 14 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 25,0 | 25,0 | 25,0 | Балаларны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 32. | Милли җәмгыять ләрнең «Дус-туганлык – иң зур байлык» фестивале | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 1 010 | 1 010 | 1 010 | 1 010 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 130,0 | 130,0 | 130,0 | Шәһәрдә һәм республикада яшәүче халыкларның мәдәни күптөрлелеген саклау һәм аңа карата позитив кыйммәтләр, хөрмәт формалаштыру |
| 33. | Туган тел фестивале | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 355 | 355 | 355 | 355 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 5,0 | 5,0 | 5,0 | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыклар телләренең телләр күптөрлелеген саклау һәм үстерү |
| 34. | Гомуми белем бирү оешмалары ның укучылары өчен милли җәмгыять ләрнең бүлмәләре буенча экскурсияләр | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Экскурсияләр саны, берәмлек | 30 | 30 | 30 | 30 | - | - | - | - | Балаларны һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 35. | Башкорт җәмгыяте белән берлектә «Карга боткасы» милли | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачы | 1000 | 1050 | 1100 | 1150 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль | 5,0 | 5,0 | 5,0 | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыклар |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | | | лар саны, кеше | | | | | бермлеге бюджеты | | | | мәдәниятенең милли күптөрлелеген саклау һәм үстерү |
| 36. | «Терендез» әрмән милли бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 200 | 210 | 215 | 220 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 5,0 | 5,0 | 5,0 | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыклар мәдәниятенең милли күптөрлелеген саклау һәм үстерү |
| 37. | Фин-угыр халыкларының «Без бер агач тармаклары» халык иҗаты фестивален оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 1000 | 1000 | 1000 | 1000 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 100,0 | 100,0 | 100,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 38. | «Шорыкйол пайрем» мари милли бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 230 | 230 | 230 | 230 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 5,0 | 5,0 | 5,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 39. | «Каз өмәсе» халык-йола бәйрәме | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 602 | 602 | 602 | 602 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 75,0 | 75,0 | 75,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 40. | «Май чабу» шәһәр бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, | 8 350 | 8 355 | 8 360 | 8 365 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге | 75,0 | 75,0 | 75,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | кеше | | | | | бюджеты | | | | |
| 41. | «Милли бәйрәмнәр» милли бәйрәмнәр буенча фольклор кич утырулар» шәһәр проекты | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 160 | 170 | 175 | 180 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 30,0 | 30,0 | 30,0 | Балаларны һәм яшьләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 42. | «Сабан туе» милли бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 17 500 | 18 000 | 18 500 | 19 000 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 332,8 | 332,8 | 332,8 | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның милли күптөрлелеген саклау һәм үстерү |
| 43. | Татарстан Республикасы көненә һәм Яр Чаллы шәһәре көненә багышланган шәһәр бәйрәмен оештыру һәм үткәрү | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 14 800 | 15 000 | 15 500 | 15 800 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 150,0 | 150,0 | 150,0 | Халыкны мәдәни-тарихи социальләштерү |
| 44. | «Идел буе этносы һәм мәдәнияте» мәдәни-белем бирү проекты | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар һәм тамашачылар саны, кеше | 125 | 130 | 135 | 140 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 72,0 | 72,0 | 72,0 | Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче халыкларның милли күптөрлелеген саклау һәм үстерү |
| 45. | «Мин – патриот» интеллектуаль уен | Башкарма комитетның | 2025-2027 | Катнашучылар саны, | 115 | 120 | 125 | 130 | Яр Чаллы шәһәре | 12,0 | 12,0 | 12,0 | Яшьләрне мәдәни-тарихи |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | яшьләр белән эшләү идарәсе | еллар | кеше | | | | | муниципаль берәмлеге бюджеты | | | | социальләштерү |
| 46. | «Тәм-том» кулинария зонасы» милли ризыклар фестивале | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучы лар саны, кеше | 100 | 110 | 120 | 130 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 35,0 | 35,0 | 35,0 | Яшьләр арасында милли ашларга һәм мәдәниятка кызыксынуны үстерү |
| 47. | «Татар квест» проекты | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучы лар саны, кеше | 150 | 155 | 160 | 165 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 15,0 | 15,0 | 15,0 | Яшьләр арасында шәһәребез һәм Республика мәдәниятен һәм тарихын өйрәнүгә кызыксынуны үстерү |
| 48. | «Серле сандык» шәһәр милли иҗат проектын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучы лар саны, кеше | 110 | 115 | 120 | 125 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 30,0 | 30,0 | 30,0 | Проектта катнашучы ларның толерант аңын формалаштыру һәм Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче һәм регион халыкларының милләтара мөнәсәбәтләрен ныгыту өчен шартлар тудыру |
| 49. | «Халкым чишмәсе» региональ яшьләр татар милли иҗат | Башкарма комитетның яшьләр белән | 2025-2027 еллар | Катнашучы лар саны, кеше | 195 | 200 | 205 | 210 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Яшьләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | фестивален оештыру һәм үткәрү | эшләү идарәсе | | | | | | | берәмлеге бюджеты | | | | |
| 50. | «Татар егете» региональ проектын оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 105 | 110 | 115 | 120 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Яшьләр арасында үз халкының мәдәниятен һәм тарихын өйрәнүгә кызыксынуны үстерү, гражданның рухи шәхесен һәм үз иленең патриотын тәрбияләү |
| 51. | Татар яшьләре форумы | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе | 2025-2027 еллар | Катнашучылар саны, кеше | 85 | 90 | 95 | 100 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Яшьләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |
| Бурычның исеме: 4. Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыруның фәнни-белем бирү һәм мәгълүмати тәэмин ителеше | | | | | | | | | | | | | |
| 52. | Дини оешмалар һәм культ корылмалары турында мәгълүматлар банкын квартал саен формалаштыру һәм актуальләш терү | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | 2025-2027 еллар | Мәгълүматлар базасын яңартулар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - | - | Шәһәрдә милләтара һәм конфессияара бердәмлеккә булышлык итү өчен уңай атмосфера булдыру |
| 53. | Туган телдә (татар, рус) иң яхшы дәрес, чаралар буенча җыентык бастырып | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2025-2027 еллар | Данәләр саны | 100 | 100 | 100 | 100 | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге | 50,0 | 50,0 | 50,0 | Балаларны һәм яшүсмерләрне мәдәни-тарихи социальләштерү |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | чыгару | | | | | | | | бюджеты | | | | |
| 54. | «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында һәм шәһәрнең массакүләм мәгълүмат чараларында чараларны анонслау, пост-релизлар бастырып чыгару | Мәдәният идарәсе | 2025-2027 еллар | Бастырып чыгарылган мәкаләләр, анонслар, телетапшырулар, интервью һәм чыгышлар саны | 18 | 19 | 20 | 21 | - | - | - | - | Толерантлык идеяләрен пропагандалау һәм тарату, милләтара һәм конфессияара бердәмлекне саклау өчен бердәм мәгълүмати киңлек формалаштыру |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы

Г.А. Шәфыйкова